Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октябрь 2022 ел №15

Әлмәт муниципаль районы Васильевка авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 нчы декабрендәге 9 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Васильевка авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Васильевка авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 нчы декабрендәге 9 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Васильевка авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт; Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урамы 32а йорты территорияләрендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Васильевка авылы башкарма
комитеты җитәкчесе Ш.М. Касыймуллин